СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 7 » апрель 2016 ел** **№ 52**

**Арча район Советының «Арча муниципаль районы бүләкләрен гамәлгә кую турында» 2006 елның 10 февралендәге 44 номерлы карарына өстәмәләр кертү хакында» 2006 елның 24 мартындагы 65 номерлы карары белән расланган «Арча районы мактаулы гражданы» исеме турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

Арча муниципаль район уставы нигезендә, Арча район Советы карар бирде:

1. «Арча муниципаль районы бүләкләрен гамәлгә кую турында» Арча район Советының 2006 елның 10 февралендәге 44 номерлы карарына өстәмәләр кертү турында» Арча район Советының 2006 елның 24 мартындагы 65 номерлы карары белән расланган «Арча районы мактаулы гражданы» исеме турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. «Мактаулы граждан» исеме Арча район Советы тарафыннан «Арча батырларын барлый» бәйрәме алдыннан бирелә.

2) 2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Исем бирү турындагы тәкъдимнәр, кирәкле документларны кушып, комиссиягә «Арча батырларын барлый» район бәйрәменә кадәр 3 (өч) айдан да соңга калмыйча җибәрелә.»

3) 2.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. «Арча районының мактаулы гражданы» исемен бирү мәсьәләсе район Советы Президиумы каравына «Арча батырларын барлый» бәйрәменә бер айдан да соңга калмыйча бер тапкыр чыгарыла. »

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г. Нуриев